РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН ГЛАВА ГАЙТАНКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ГАЙТӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

423014, РТ, Нурлатский район, с. Гайтанкино, ул. Садовая, дом 17,
Тел. 8 (84345) 3-98-01

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» октябрь 2023 ел № 2

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлегенең Кәкре Атау торак пунктында гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елның 1 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Гайтән авыл җирлеге Кәкре Атау авылында Үзәк тыкрык, 2нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кәкре Атау авылында Үзәк урамы буенча 1-55нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2023 елның 2 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Гайтән авыл җирлеге Кәкре Атау авылында Үзәк тыкрык, 2нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кәкре Атау авылында Үзәк урамы буенча 56-124нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2023 елның 3 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Гайтән авыл җирлеге Кәкре Атау авылында Үзәк тыкрык, 2нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кәкре Атау авылында Полевая урамы буенча 1-59нчы йортлардан, Үзәк тыкрыгы буенча 1-14нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә

4. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль буенча башкарырга.

5. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2024 елда Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлеге Кәкре Атау авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче һәр балигъ булган кешедән 4000 сум

күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Кщкре Атау эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән төзелеш контроле өчен түләүне дә кертеп сезонлы карап тоту.
2) Кәкре Атау торак пунктында күперне ремонтлау.
3) Гайтән торак пунктында урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү.
4) Гайтән торак пунктында су белән тәэмин итү чыганагына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү.
5) Гайтән торак пунктында паркны төзекләндерү (эскәмияләр сатып алу һәм урнаштыру, үсентеләр сатып алу).
6) Кәкре Атау торак пунктында күперне ремонтлау

« РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/rus/nurlat_poselenia.htm, бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кәкре Атау авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга

8. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Гайтән авыл җирлеге башлыгы Н. В. Авдеева